СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы 422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

от 20июня 2023 г. — №2-24

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге муниципаль милкенә карата концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Ишки авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Ишки авыл җирлеге башкарма комитетына коммуналь инфраструктура һәм башка коммуналь хуҗалык объектларына, шул исәптән су белән тәэмин итү объектларына, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системаларына, мондый системаларның аерым объектларына хезмәт күрсәтүгә концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирергә.

2. 1 нче кушымтада бирелгән күчемсез мөлкәтне концессион килешү объектлары итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән (басылып чыккан) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районыны Ишки авыл җирлеге башлыгы Р.К.Хафизовка йөкләргә.

Ишки авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы — /Р.К.Хафизов/

1 нче кушымта

Концессион килешү объектлары, шул исәптән техник-икътисадый күрсәткечләре, техник халәте, хезмәт срогы

| № п/п | объектның исеме | Кадастр номеры | урнашу урыны адресы ( торак пункт/ур.) | Техник параметрлар (мәйдан/диаметр/биеклек/озынлыгы һ.б.) | Гамәлгә керү елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ишки авылы Суэтем башнясы | 16:26:390101:591 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы,Ишки авыл жирлеге, Ишки авылы | Биеклеге 12м | 1975 |
| 2 | Ишки авылы Суэтем башнясы | 16:26:050101:512 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Ишки авыл жирлеге, Ишки авылы | Биеклеге12м | 1975 |
| 3 | Васильево авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4816 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Ишки авыл жирлеге, Васильево авылы | Озынлыгы 2763м | 1993 |
| 4 | Ишки авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4371 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Ишки авыл жирлеге, Ишки авылы | Озынлыгы 2860м | 1975 |
| 5 | Ишки авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:050101:513 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Ишки авыл жирлеге, Ишки авылы | Озынлыгы 3320м | 1975 |

Ишки авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /Р.К.Хафизов/